ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дмитрова, д.2,
с.Ютаза, 423962

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Дмитров урамы, 2 йорт,
Ютазы авылы, 423962

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.mailto:adm.jutaza@tatar.ruru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 3**

**КАРАР**
**23 ноябрь 2020 ел**

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлегенең Ютазы Кымыз белән дәвалау торак пунктында
2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә кабул ителгән 8 санлы карары белән Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Ютазы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**К А Р А Р И Т Т Е:**

1.ТР, Ютазы муниципаль районы, Ютазы Кымыз белән дәвалау бистәсе, Солнечная урамы, 1В йорт адресы буенча урнашкан кымыз ясау цехы бинасы янында 2020 елның 1 декабрендә 14.00 сәгатьтә 2021 елда Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы Кымыз белән дәвалау торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Кымыз белән дәвалау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән, балачактан инвалид булган, I һәм II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

1) Ютазы Кымыз белән дәвалау торак пунктының Солнечная урамы буенча янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Ютазы авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatar.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов